СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.2, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 2 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№3-23 13 июнь 2023ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 апрелендәге 13-46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында” Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында"2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы федераль законнар, “Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 2015 елның 30 апрелендәге “Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеген раслау турында" 13-46 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә, 1 пунктта һәм 1 нче кушымтада "в сети "Интернет" челтәрендә” сүзләрен " рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге
Советы рәисе Степанов С.Н.